**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 сентябрь № 717

г. Казань

«Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 июнендәге 176-ФЗ номерлы Федераль законны Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

түбәндәгеләрне бирүне тәэмин итәргә:

2015 елның 1 октябреннән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган куллану нормативларын исәпкә алып, гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташламаларны;

2015 елның 1 октябреннән 2016 елның 31 мартына кадәр уртача айлык керемнәре зурлыгы 20 000 сумнан артмаган социаль ярдәм чараларын алучыларның аерым категорияләренә әлеге карар белән расланган Адреслылык шартларында социаль ярдәм чараларын бирүгә күчү белән бәйле үз чыгымнары үсүне тигезләүгә компенсация турында нигезләмә нигезендә адреслылык шартларында социаль ярдәм чараларын бирүгә күчү белән бәйле үз чыгымнары үсүне тигезләүгә компенсацияне (алга таба – компенсация);

2015 елның 30 сентябренә кадәр торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә халыкка социаль ярдәм күрсәтү чаралары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган кулланма программалы продуктын эшләп бетерү буенча техник биремне эшләргә;

гражданнарның аерым категорияләренә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә социаль ярдәм күрсәтү чараларын бирү өлешендә Россия Федерациясе закон актларына кертелгән үзгәрешләр буенча халык, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар арасында аңлату эшләре алып барырга;

гражданнарның аерым категорияләренә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә социаль ярдәм күрсәтү чараларын бирү өлешендә һәм компенсация билгеләү тәртибе өлешендә федераль законнар нормаларын аңлату мәсьәләләре буенча халыкны кабул итүне тәэмин итәргә;

халыкны кабул итү белән мәшгуль белгечләр укытуны оештырырга.

2. Теркәлгән Адреслылык шартларында социаль ярдәм чараларын бирүгә күчү белән бәйле үз чыгымнары үсүне тигезләүгә компенсация турында нигезләмәне расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әгәр торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә социаль ярдәм күрсәтү чаралары күләме кимү зурлыгы 2015 елның октябрендә 300 сум һәм күбрәк булса, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә социаль ярдәм күрсәтү чаралары күләме 2015 елның октябрендә 300 сумга кими;

әгәр торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә социаль ярдәм күрсәтү чаралары күләме кимү зурлыгы 2015 елның ноябрендә 500 сум һәм күбрәк булса, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә социаль ярдәм күрсәтү чаралары күләме 2015 елның ноябрендә 500 сумга кими;

2015 елның 1 октябреннән компенсация алу хокукын рәсмиләштерү 2015 елның 1 октябреннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр территориаль социаль яклау органы раслаган һәм счет-фактураларда урнаштырылган график буенча гамәлгә ашырыла;

2015 елның 1 октябренә торышы буенча торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр алучы булган гражданнарга компенсация билгеләү гражданның территориаль социаль яклау органына мөрәҗәгатеннән башка гына гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына 2015 елның 30 сентябренә кадәр торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә халыкка социаль ярдәм күрсәтү чаралары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган кулланма программалы продуктын эшләп бетерүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

2015 елның сентябре өчен счет-фактураларда гражданнарның аерым категорияләренә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә социаль ярдәм күрсәтү чараларын бирү өлешендә Россия Федерациясе закон актларына кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итәргә;

социаль яклау органнарына халыкны кабул итүдә ярдәм күрсәтергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\717.docx